| | |
|---|---|
| ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>***БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ***<br>***БУА ШӘҺӘР СОВЕТЫ*** | РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>***БУИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН***<br>***БУИНСКИЙ ГОРОДСКОЙ СОВЕТ*** |

# КАРАР
# РЕШЕНИЕ

14 ноябрь 2018 ел № 3-37

«Физик затлар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының 2014елның 14 ноябрендәге 1-39 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Буа шәһәр Советы

**КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:**

I. «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының 2014елның 14 ноябрендәге 1-39 номерлы карарына (2015 елның 21 маендагы 3-45 номерлы, 09.10.2015 № 6-2 номерлы карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. 2 пункт:

2 һәм 3 пунктчаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) 0,2 процент нисбәтендә:

фатирга;

фатир өлешләренә;

бүлмәгә;

3) 0,3 процент нисбәтендә:

торак йортларга;

торак йорт өлешләренә;

мондый объектларның проектланган билгеләнеше торак йорт булса, тәгәлләнмәгән төзелеш объектлары;

составына бер генә торак йорт кергән бердәм күчемсез комплекслар**.»;**

1.2. 4 абзац:

2 пунктның 3 пунктчасында «бер торак бина (торак йорт)» сүзләрен «бер торак йорт» сүзләренә алмаштырырга.

1.3.карар тексты:

түбәндәге редакциядә 4 һәм 5 пунктлар өстәргә:

«4. Физик затлар мөлкәтенә салым түләүдән түбәндәгеләрне азат итәргә:

4.1. 18 яшькә кадәрге өч һәм аннан да күбрәк баласы булган

4.2. әлеге пунктның 4.1 пунктчасында күрсәтелгән гражданнарның балалары.

5. Салым ташламасы салым салу объектларының түбәндәге төрләренә карата бирелә:

1) Фатирлар, фатир (бүлмәләр) яки торак йорт өлешләре, торак йорт өлешләре.

Салым ташламасы гаиләгә туры килә торган салым салуның бер объектына карата салым түләүчене сайлау буенча бирелә. Салым ташламасы Буа муниципаль районының Буа шәһәре территориясендә даими яшәүче салым түләүчеләргә салым түләүче тарафыннан салым салучы

милкендәге һәм эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланылмый торган салым салу объектына карата салым суммасы түләнергә тиешле күләмдә салым түләүчеләргә бирелә.

Салым ташламасына хокукы булган зат салым органына ташламалар бирү турында гариза һәм салым ташламасына хокукны раслый торган документлар тапшыра. Салым ташламасы бирелә торган сайланган объектлар турында хәбәрнамә салым түләүче тарафыннан салым органына ел 1 ноябренә кадәр тапшырыла, ул салым чорыннан башлап шушы объектларга карата салым ташламасы кулланыла торган салым чоры булып санала.»;

1.4. 4, 5 һәм 6 пунктларны 6, 7 һәм 8 пунктлар дип санарга.

II. Әлеге карар 2018 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә, ләкин Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы, http://pravo.tatarstan.ru/ адресы, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://buinsk.tatarstan.ru адресы буенча рәсми басылып чыккан һәм урнаштырылган көннән алып 1 айдан да иртәрәк булмаган вакытта.

III. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Буа муниципаль районының Буа шәһәре башлыгы М.А. Җаббаров